СОВЕТ ИСКЕ-КАЗАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Куркачи ул. Клубная, 4

РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ-КАЗАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык авылы, Клуб урамы, 4

тел./факс 8(84365) 70-700 ,e-mail: Ikaz.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**27 август, 2021 ел** **№ 31**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау районы прокуратурасының 2021 елның 27 маендагы 02-01-26-2021 номерлы таләпләре нигезендә, муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый анализ һәм мониторинг нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске Казан авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Иске-Казан авыл җирлеге Советының 2021 елның 25 мартындагы 20 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә кермәгән яшел утыртмаларны кисү тәртибе турында нигезләмә»гә (Советның 22.04.2021 № 25 карары редакциясендә) 3 бүлекнең 3.6. пунктына, түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«3.6. Эшләр башкаруга рөхсәт алганда, аның мәнфәгатьләрендә яшел утыртмалар юкка чыгарыла торган Гариза бирүче, әлеге Нигезләмә нигезендә яшел утыртмаларны кискән өчен компенсация бәясе күләмендә түләүләр кертергә тиеш.»;

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-арес буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Иске-Казан авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе Г.Р.Закировага йөкләргә.

Совет рәисе,
Иске-Казан авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Закирова